ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2019 г.Лениногорск № 2193

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 17 сентябрендәге 357 номерлы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы карары (2014 елның 5 февралендәге 24 номерлы, 2014 елның 12 февралендәге 39 номерлы, 2016 елның 13 апрелендәге 571 номерлы, 2017 елның 2 мартындагы 211 номерлы, 2017 елның 21 декабрендәге 1851 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы оешмаларга йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 17 сентябрендәге 357 номерлы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы

карары (2014 елның 5 февралендәге 24 номерлы, 2014 елның 12 февралендәге 39 номерлы, 2016 елның 13 апрелендәге 571 номерлы, 2017 елның 2 мартындагы 211 номерлы, 2017 елның 21 декабрендәге 1851 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы оешмаларга йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә түбәндәге өстәмә кертергә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм караган өчен ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше» таблицасына өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яшәү минимумыннан түбән (күп балалы гаиләләр өчен) | 0 | 0 | 0 |

2.Әлеге карарны рәсми Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет- сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72